| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ**<br>**26.04.2019** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 380** |

«Зеленодольск муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесенең 2018 елгы эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисабы хакында

«Зеленодольск муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе рәисе С.В.Кадыйрованың «Зеленодольск муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесенең 2018 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре турындагы докладын тыңлап һәм фикер алышканнан соң, Зеленодольск муниципаль районы Советы билгеләп үткәнчә, «Зеленодольск муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесе үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында» 2012 елның 17 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, «Зеленодольск муниципаль районы контроль-хисап палатасы турында» нигезләмәгә таянып эш итте

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы Советы депутатларының тәкъдимнәрен исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. «Зеленодольск муниципаль районының Контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесенең 2018 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисабын исәпкә алырга (кушымта итеп бирелә).
2. 2018 ел өчен «Зеленодольск муниципаль районы Контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесенең эшен канәгатьләнерлек дип танырга.

3. «Зеленодольск муниципаль районының Контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесенең 2018 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисабын Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru урнаштырырга

**Зеленодольск муниципаль**
**районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**